Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пунктында гражданнар җыены карары

2024 елның 24 ноябре № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2024 елның 24 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлар, мобилизацияләнгән һәм контракт буенча хәрбиләр, күпбалалы гаиләләрдән тыш, 2025 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Аккүл авылының Күпер урамындагы вак таш җәелгән юллардагы чокырларны ремонтлау; Аккүл авылының Күпер урамындагы, Колхоз урамындагы, Комсомол урамындагы юлларны кардан чистарту);
2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Аккүл авылында балалар мәйданчыгы урнаштыру; Аккүл авылында гомуми файдаланудагы территорияләрдә үлән чабу; триммер өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу) соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 326 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 166 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 166 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлар, мобилизацияләнгән һәм контракт буенча хәрбиләр, күпбалалы гаиләләрдән тыш, 2025 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Аккүл авылының Күпер урамындагы вак таш җәелгән юллардагы чокырларны ремонтлау; Аккүл авылының Күпер урамындагы, Колхоз урамындагы, Комсомол урамындагы юлларны кардан чистарту);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Аккүл авылында балалар мәйданчыгы урнаштыру; Аккүл авылында гомуми файдаланудагы территорияләрдә үлән чабу; триммер өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу) соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ивановка авылы, Яшьлек ур., 5 й., Аккүлав., Колхоз ур., 16Б; Медведкаав., Юл ур., 32; Михайловкаав., Үзәк ур., 4, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Ивановка авыл җирлеге башлыгы А.П.Бодряева